УПРАВЛЕНИЕ ЗАГС
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Ахтямова, дом 14,
город Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ
ГХАТ ИДАРӘСЕ
Әхтәмов урамы, 14 нче йорт,
Казан шәһәре, 420021

Тел./ факс: (843) 293-14-89, zags@tatar.ru, zags.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**Казан шәһәре**

**«14» июль 2015 ел** **№ 49**

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү Идарәсенә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибен раслау хакында**

“Татарстан Республикасында гражданнарның мәрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 2003 елның 12 маендагы № 16-ЗРТ Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү Идарәсенә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау бердәм тәртибен булдыру күзлегеннән чыгып, **боерык бирәм**:

1. Әлеге боерыкка кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү Идарәсенә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.
2. Хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлегенә әлеге Тәртипнең 2.4 пункты нигезендә ярты елга бер тапкыр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү Идарәсенә (алга таба – Идарә) килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясарга.
3. Мәгълүмати ресурслар секторына ярты елга бер тапкыр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү Идарәсенә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализны Идарәнең рәсми сайтында урнаштырыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземә йөклим.

**Идарә башлыгы** **А.Р.Шәвәлиева**

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
граждан хәле актларын
теркәү Идарәсе
“14” июль 2015 ел № 49
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты**
**граждан хәле актларын теркәү Идарәсенә**
**килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү Идарәсенә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе (алга таба – Тәртип) “Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 2003 елның 12 маендагы № 16-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты граждан хәле актларын теркәү Идарәсенә (алга таба – Идарә) килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау бердәм тәртибен булдыру максаты белән эшләнелде.

1.2. Әлеге Тәртип Идарәгә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау критерийларын һәм үткәрү шартларын билгели.

## II. Идарәгә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе

2.1. Идарәгә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлеге тарафыннан ярты ел һәм ел йомгаклары нигезендә башкарыла. Идарәгә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренә ясалган анализ нәтиҗәләренә таянып отчет периодында Идарәгә килгән гражданнар мөрәҗәгатьләренә ясалган анализ турында отчет (алга таба – Отчет) төзелә.

2.2. Әлеге Отчет «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Идарәнең рәсми сайтында “Халык мөрәҗәгатьләре һәм гражданнарны кабул итү” бүлегендә урнаштыру өчен отчет периодыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр мәгълүмати ресурслар секторына җибәрелә.

2.3. Мәгълүмати ресурслар секторы әлеге Отчетны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Идарәнең рәсми сайтында “Халык мөрәҗәгатьләре һәм гражданнарны кабул итү” бүлегендә отчет периодыннан соң килүче айның 17 числосына кадәр урнаштыра.

2.4. Отчет түбәндәге мәгълүматтан торырга тиеш:

кабул ителгән, бүтән адрес белән җибәрелгән, карап тикшерелгән язма мөрәҗәгатьләр саны;

электрон документ формасында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр саны;

гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре;

шәхси кабул ителгән гражданнар саны;

гражданнарны шәхси кабул итү буенча вәкаләтле вазыйфаи затлар;

вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан башка урыннарда үткәрелгән гражданнарны кабул итүләр саны;

мөрәҗәгатьләр тематикасы;

мөрәҗәгатьләрне тикшереп караганнан соң күрелгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән хокукый норматив һәм башка төрле актларны кабул итү турында мәгълүмат (булган очракта).

## III. Йомгаклау нигезләмәләре

3.1. Әлеге Тәртипкә кертелә торган барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Идарә башлыгы боерыгы белән расланалар.